| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 3 ноябре № 21

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы « Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлегенең Яңа Елховой авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны кардан чистарту;
2. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:
- «Чатра» чишмәсенә капиталь ремонт;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Яңа Елховой авылы, Чишмәле урамы, Бохар авылы Авангард урамы,22 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.Ф.Хәбибуллин